ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында «якынча» сүзен «федераль» сүзенә алмаштырырга;

2) 10 статьяның 1 өлешендә «якынча уку-укыту программаларын» сүзләрен «федераль төп гомуми белем бирү программаларын һәм урта һөнәри белем бирүнең якынча уку-укыту программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

3) 11 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләреннән соң «федераль башкарма хакимиятнең гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм аны гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органы белән килештереп» сүзләрен өстәргә;

4) 15 статьяда:

а) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда яшәүче сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучылар дәүләтнең тулы тәэминатында була һәм тукланy, кием-салым, аяк киеме, йомшак һәм каты инвентарь белән тәэмин ителә. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда яшәмәүче сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучылар

мондый оешмаларны гамәлгә куючылар тарафыннан федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы бюджетының, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка финанслау чыганаклары исәбеннән ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин ителә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

«$6^1$. Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары һәм муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан укыту өйдә оештырылган сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибе, шул исәптән ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алмаштыру мөмкинлеге, тиешенчә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәргә:

«$7^1$. I, II яки III төркем инвалидлар дип танылган затлар, урта һөнәри белем яисә югары белем алганнан соң, федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы бюджетының, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән башка һөнәр, белгечлек яисә әзерлек юнәлеше буенча Федераль законда тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белемне беренче тапкыр алучы затлар өчен билгеләнгән тәртиптә кабат тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алырга хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 01 декабрь
№ 84-ТРЗ